ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.05.2023 ел. Баулы шәһәре №114

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022-нче елның 14 октябрендәге
213 номерлы карары белән расланган Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль районында
"Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын
гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү
оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү"
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010-нчы елның 27нче июлендәге 210-ФЗ номерлы карар белән кабул ителгән Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1.Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 -нче елның 14 октябрендәге 213 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2- нче бүлектә «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»:

2.8.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яисә шәхесне раслаучы башка документ, Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, мәгълүмати технологияләр кулланып күпфункцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән, 2006-нчы елның 27 июлендә 149-ФЗ номерлы карар белән кабул ителгән Федераль законның 14.1 статьясындагы 18-нче өлешендә каралган “Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында».

Гаризаны Бердәм дәүләт хезмәтләре порталы һәм/ яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәргәндә, кулланучы тарафыннан Бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында хисап язмасын төзегәндә һәм раслаганда күрсәтелгән гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ турында мәгълүмат тапшырыла. Күрсәтелгән мәгълүматлар Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә сорауны юнәлтү юлы белән тикшерелә ала»;

2.11.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11.1. Электрон образлары элек 27.07.2010-нчы елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы карары белән кабул ителгән Федераль законның 16-нчы статьясындагы 1-нче өлешендәге 7.2 пунктына «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» ярашлы рәвештә расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазьдә күрсәтү. Кайбер очраклардан тыш, әгәр мондый документларга билгеләр салу яки аларны алу муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле шарт булып торса яки муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тәкъдим ителмәгән яки гамәлгә ашырылмаганнарын гамәлгә ашыруны исәпкә алмаганда».;

3-нче бүлектә «Административ процедураларны үтәүнең эзлеклелеге һәм вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкнең читтән торып административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буенча, гомуми билгеләр белән берләшкән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә ала»:

3.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«-хезмәт күрсәтү турында сорау бирү өчен кабул итүгә язылу, шулай ук хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган очракларда, кабул итүгә бер үк вакытта язылу белән сорау җибәрү мөмкинлеге.»;

3.3 пунктның 5 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бердәм дәүләт хезмәтләре порталына һәм/яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталына гариза формалаштырганда гариза бирүче тәэмин ителә:

а) сорауны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

б) хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүченең, бер уртак соравы булганда, сорау җибәрүне бер электрон формада тутыру мөмкинлеге;

в) электрон сорау формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

г) элек электрон формада кертелгән сорауларны кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән керткәндә хаталары килеп чыкканда һәм кабат кертү өчен, сорауның электрон формасына керткәндә саклап калу;

д) «электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган мәгълүматны кулланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүмат кертелүгә кадәр сорауның электрон формасы кырларын тутыру (алга таба Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы), һәм бердәм порталда, хезмәтләр порталында яки рәсми сайтларда басылган мәгълүматлар, Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә;

е) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, сорауның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

ж) гариза бирүченең Бердәм дәүләт хезмәтләре порталы һәм/яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша элек бирелгән сорауларга бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган сорауларга 3 айдан да ким булмаган вакыт эчендә керү мөмкинлеге.

з) Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында гариза бирүченең профилендә урнаштырылган мәгълүматлар нигезендә электрон формадагы гариза кырын автомат рәвештә тутыру мөмкинлеге.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров